КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 11 гыйнвар г.Казань № 2

«Ядкәр» (Хәтер) генеалогия үзәге» коммерциягә карамаган автоном тарих-шәҗәрә тикшеренүләре оешмасын төзү турында

Татарстан Республикасы халыкларының генеалогик тикшеренүләренә булышлык күрсәтү, тарихи хәтерен торгызу максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының «Ядкәр» (Хәтер) генеалогия үзәге» коммерциягә карамаган автоном тарих-шәҗәрә тикшеренүләре оешмасын (алга таба – автоном оешма) төзү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына:

автоном оешманың гамәлгә куючысы булырга;

60 көн эчендә автоном оешманың уставын расларга һәм аны законнар белән билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә;

автоном оешма төзүгә бәйле башка чараларны үткәрергә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин